РАСЛЫЙМ
“К. Насыйри туган җирен торгызу”
фонды башкарма директоры
______________А.Н.Гобәйдуллина
18.11.2024 ел

Каюм Насыйриның 200 еллыгына багышланган
Х республикакүләм мәсәл иҗат итүчеләр бәйгесе
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

I.Гомуми нигезләмә

Иҗат эшләре бәйгесе бөек татар мәгърифәтчесе, галим Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан оештырыла.

II. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Бәйгенең максаты: бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри шәхесе, аның бай иҗатын өйрәнү, әдәби мирасын пропагандалау, үстерү, саклау , галимгә карата хөрмәт һәм кызыксыну уяту.

2.2. Бәйгенең бурычлары: К.Насыйриның зур әдәби мирасы белән таныштыру; шәхеснең иҗатына кызыксыну уяту, мәхәббәт тәрбияләү; катнашучыларның иҗат мөмкинлекләрен ачу, үстерү; әдәби татар телендә аралашу, иҗат итү өчен шартлар тудыру.

III. Бәйгене гамәлгә куючылар һәм оештыручылар

3.1. “Каюм Насыйри туган җирен торгызу” фонды һәм Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты.

IV. Бәйгедә катнашу тәртибе

4.1. Иҗат эшләре бәйгесендә **мәсәлләр** иҗат иткән 18 яшьтән өлкәнрәк һәркем катнаша ала.

Мәсәл — гыйбрәтле, көлкеле характерда булган шигъриятле яки сибелүчән әдәби әсәр.

4.2. Иҗат эшләре Word форматында 14 нче шрифт белән 1 биттән дә артмаган күләмдә электрон вариантта җибәрелергә тиеш.

4.3. Бәйгедә катнашырга теләк белдерүчеләр билгеләнгән үрнәктәге гаризаны (Кушымта №1) һәм иҗат эшләрен shaki-ramil@yandex.ru әрҗәсенә «Бәйгегә» дигән тамга белән 15.01.2025 соңга калмый җибәрә. Авторның бәйгедә катнашуга гариза юллавы аның катнашу шартлары белән килешүен, үзе хакындагы шәхси мәгълүматны куллануга ризалык бирүен аңлата. Барлык эшләр дә татар телендә булырга тиеш.

4.4. Бәйгедә катнашу бушлай.

V. Авторлык хокуклары

Авторларның бәйгегә тапшырган иҗат эшләре соңыннан оештыру комитеты тарафыннан түбәндәге максатларда файдаланылачак:

- X республикакүләм иҗат бәйгесе җыентыгын бастыру;
- интернетта, масса-күләм мәгълүмат чараларында, иҗади проектларда.

VI. Бәйгене үткәрү вакыты һәм тәртибе

Бәйгедә катнашу тәртибе :

– гаризаларны һәм эшләрне кабул итү (2025 нче елның 15 нче гыйнварына кадәр);

Жюри комиссиясе иң яхшы эшләрне сайлап ала, нәтиҗәләр чыгара. Бәйге нәтиҗәләре 3 февральдә "Туган авылым-Кече Шырдан" ВК төркеменә эленәчәк (сылтама https://vk.com/club90300419)

Бәйге нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр (Гран-при, 1, 2, 3 урыннар) һәм катнашучылар электрон дипломнар белән бүләкләнә. Җиңүчеләр бүләкләнү өчен Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылына чакыру алачак.

VII. Бәйгене йомгаклау

8.1. Бәйге эшләрен эксперт комиссиясе карый.

8.2.Эксперт комиссиясенең эшенә протокол языла һәм нәтиҗәләр раслана.

8.3.Җиңүчеләр Гран-при, I, II, III дәрәҗәдәге дипломнар һәм истәлек бүләкләре белән бүләкләнәләр.

VIII. Бәйгене оештыру комитеты адресы

Оештыру комитеты адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Заслонова урамы, 5 нче йорт, офис "Акведук"

E-mail: shaki-ramil@yandex.ru (Шакиров Рамил Фрон улы)

Кушымта №1.

Бәйгедә катнашу өчен гариза формасы

Катнашучының (тулысы белән) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме	
Яше	
Яшәү урыны (шәһәр, район, авыл)	
Эш урыны	
Әсәрнең (эшнең) исеме	
Катнашучының эл. адресы, телефоны	